СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*11 ноябрь, 1998 ел.*
**ЧӘРШӘМБЕ**

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 128 (8285)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## АВЫЛ БАТЫРЛАРЫ КАЗАНГА ҖЫЕЛА

14 - 15 ноябрь көннәрендә Казанның "Батыр" физкультура йортында Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгы Спорт комитеты һәм Милли көрәш федерациясе белән бергәләп бәйге үткәрә.

Исеменнән үк күренгәнчә, анда фәкать авыл җирләрендә яшәүче көрәшчеләр генә катнаша. Көч сынашулар 60, 70, 80, 90, 100 килограммга кадәр һәм авыр үлчәүдә үткәрелә. 50 яшьтән өлкән ветераннар ике үлчәүгә бүленеп бил алыша (90 кг һәм аннан авыррак үлчәүдә).

***Ярышларга килү көне - 14 ноябрь. Сәгать 11 дән 13 сәгатькә кадәр мандат комиссиясе, үлчәнү була һәм 14 сәгатьтә бил алышулар башлана.***

# «РАЙОННЫҢ АЛТЫН ФОНДЫ»





***7 ноябрь көнне Яшьләр йортында район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин катнашында районның алтын фонды - элеккеге җитәкчеләр, актив белән "Чын күңелдән" дип исемләнгән очрашу үтте.***




***Бу очрашу барышында минем хәтергә "Зирәк карт" әкияте килеп төште. Хәтерлисезме? Борын заманда бер патшалыкта 80 яшьтән узган өлкәннәрне үтерү гадәткә кертелгән. Берәү үзенең әтисен бу кансыз законнан саклап калырга теләгән. Күп сынаулар, кичерешләрдән соң, бәхетле тәмамланган әкиятнең морале шундый: илгә яшьләр көч - куәте генә түгел, өлкәннәр акылы, картлар тәҗрибәсе һәм зирәклеге дә кирәк...***

Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның Яшьләр үзәгендә район аксакаллары белән очрашуында акыллы бу фикер кызыл җеп булып сузылды. Кунаклар озак көттермәделәр. Заманында күбесе Ватан азатлыгы өчен көрәшкән, партия кушуы, хезмәт вазифасы буенча көнне, төнне онытып эшләгән, иң беренче планга халык мәнфәгатен куеп яшәргә өйрәнгән корыч буын үзләре хакында искә төшерүләрен күптән көткән бугай. Әнә үз чорында Россия Федерациясенең иң атаклы райпо рәисләреннән Салих Сәйфулла улы Идиятуллин, 30 елга якын район финанс бүлеге мөдире булган Һ.С.Рәхимов, район Советы план бүлеген җитәкләгән К.Ә.Калмурзин, атаклы төзүче, 547 нче ПМК башлыгы А. Г. Ишкиниев атлыйлар. Арырак - авыл хуҗалыгы белгечләре, элеккеге хуҗалык җитәкчеләре: С.С.Гафуров, М.И.Щербаков, П.И.Ильин, Х.К.Кәлимуллин, Н.И.Маслаков, М.М.Мифтахов, З.Ш.Бильданов. "Малайлар, сез нинди чибәрләр!" дип, колачын җәеп залга килеп керүче К.В.Изотова, әле дә яшьләрчә чибәр һәм затлы Г.А.Мокеева белән М.Д.Кархалева һәм тагы бик күпләр - 30дан артык кеше - һәммәсе безнең буын өчен легендар шәхесләр, кадерле затлар иде. Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да сүзен аларга хөрмәт белән: "Сез район һәм шәһәрнең алтын фонды" дип мөрәҗәгать итеп башлады.

- Сезнең белән күптән күрешәсем килә иде. Хәзер нәкъ менә сезнең авторитетыгыз кирәк чак, чөнки илдә икътисадый гына түгел, сәяси кризис та бара.

Фатих Сәүбәнович аннан соң республикада, райондагы икътисадый торышны бәян итте. Нурлат районының бүген дә иҗади хезмәттә, җитештерүдә яшәвен саннарда һәм фактларда күрсәтте. Якын киләчәккә билгеләнгән иң төп ниятләрдән Зүзәй нефть эшкәртү, Төрнәс спирт заводларына зур киләчәк баглануын әйтте. Аерым бер горурлык белән авыл хуҗалыгында барган үзгәрешләргә тукталды, районның бу юнәлештә тәҗрибә уртаклашу өчен күп регионнарга өйрәнү мәктәбе булуын да өстәде.

Әлбәттә, бүген табын артына җыелган кунаклар боларның һәммәсеннән хәбәрдарлар иде! Хакимнән соң сүз алган элеккеге колхоз рәисләре - 29 ел җитәкчелек иткән С.С.Гафуров һәм 30 еллык рәис Н.И.Маслаков республикада, районда барган сәясәтне хуплап телгә алдылар, киңәшләрен дә бирергә онытмадылар. Аннан чибәрлеге, затлылыгы, эшкә сәләте белән чордашларын гашыйк иткән Г.А.Мокеева, легендар мәдәният хезмәткәре К.В.Изотова сүз алдылар, шундый очрашуны оештырган өчен хакимгә зур рәхмәт белдерделәр. "Нурлатлылар Сезгә бик ышаналар, ул тойгы Сезгә көч бирергә тиеш. Ә без - биредә җыелганнар - Сезгә хәлдән килгән ярдәмне күрсәтергә әзербез",- дип тәмамлады сүзен районның өлкәннәр советы рәисе, атказанган сәүдә хезмәткәре С.С. Идиятуллин. Аңа П.И. Ильин кушылды.

Һәм барлык чыгыш ясаучыларның да уртак фикере булып яңгыраган тагы бер нәрсә бар иде: ул элеккеге райком секретаре Г.К.Гыйматдиновның якты истәлеген хөрмәт белән искә алу.

"Ул эшли белгәннәрне саклый да, яклый да белде, без аның киң кодрәтен, ярдәмен тоеп үстек, яшәдек, эшләдек",- диделәр өлкәннәр. Шуңа Фатих Сәүбәновичның мөхтәрәм Гыйматдинов ядкарен искә алу турында тәкъдиме һәркемдә чын күңелдән хуплау тапты.

**(Ахыры 2нче биттә).**

**Вакытлы матбугатка язылыр чак**

## ҮЗӘК МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘ

**Татарстан Республикасы Татар иҗтимагый үзәге Яр Чаллы шәһәре бүлеге вакытлы матбугатка язылу чорында республика һәм шәһәр предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре, банклары башлыклары, татар эшмәкәрләре, хезмәт ияләрен социаль яклау бүлекләре, вакытлы матбугатны яздыру һәм тарату агентлыклары җитәкчеләре адресына мөрәҗәгать белән чыкты.**

**Анда түбәндәге юллар бар:**

"Яр Чаллы Татар иҗтимагый үзәге бүген... республикабызның, шәһәрнең зыялы эшмәкәрләренә татар басмаларына ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Ул ярдәм төрле формада булырга мөмкин. Әмма һәр газета - журналның язмышын аның тиражы, ягъни укучылары саны билгели. Шуңа күрә җәмгыятьнең аз яклanган катламына - пенсионерларга, инвалидларга, эшсезләргә аларның яраткан газета - журналларын яздыру - бу очракта ярдәмнең иң отышлысы һәм саваплысы булыр иде...

Бүген без шәһәр, республика предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре, акционерлык җәмгыятьләре, банклар җитәкчеләренә дә мөрәҗәгать итеп болай диясебез килә: эшче - хезмәткәрләрегезне һичьюгы тормыш белән бергә атлау, һәрдаим хәбәрдар булып яшәү бәхетеннән аермагыз, аларны киләсе ел өчен газета - журналларга яздыру чараларын күрегез.

Чаллы Татар иҗтимагый үзәге шәһәр һәм республика элемтә хезмәткәрләре арасында "1999 ел өчен татар басмаларына иң күп яздырган бүлекчә һәм почтальон" дигән мактаулы исемнәр өчен конкурслар да тәкъдим итә. Аңа 15 декабрьдә нәтиҗә ясалачак, үзәк җиңүчеләргә бүләкләр дә билгели."

**Хәбәрләшү өчен үзәкнең адресы: Яңа шәһәр, 17/10, Чаллы Татар иҗтимагый үзәге.**
**Телефон: 52-56-06.**

## «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛДЫГЫЗМЫ ӘЛЕ?

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

## Владимир ИВАНОВ,

***Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлеге начальнигы, милиция полковнигы:***

# «МИЛИЦИЯНЕҢ БУРЫЧЫ БЕР: ҖИНАЯТЬЧЕЛЕККӘ КАРШЫ КӨРӘШҮ»



Кичә, 10 ноябрьдә илнең хокук тәртибе сагында торучылар Россиядә эшче - крестьян милициясенең оешуына 81 ел тулуны билгеләп үттеләр. Төзелүенең беренче көннәреннән үк милиция законлылыкны һәм хокук тәртибен тайпылышсыз үтәүдә, гомумхалык һәм гражданнарның шәхси милкен саклауда, шәхеснең законда нығытылган ирекләрен һәм хокукларын тәэмин итүдә дәүләтнең төп таянычы булды.

Милициянең бүгенге буыны шушы службаның тарихындагы данлы сәхифәләр белән горурлана, өлкән хезмәттәшләренең тәҗрибәсеннән иң яхшы якларны куллanылышка алырга тырыша, милиция ветераннарының данлы традицияләрен һәм васыятьләрен ишәйтә. Без аларга бүгенге көндә дә зур рәхмәтле һәм, бәйрәм белән котлап, озын гомер һәм күңел көрлеге телибез.

Элек гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы, сугыштан соңгы җимереклек һәм ачлык чорлары җитди сынау чоры булган кебек, Россия дәүләтенең үзгәртеп кору һәм кыргый капитализм урнашу дип йөртелә торган хәзерге тарихында да милиция иң мәкерле һәм көтелмәгән рәвешләргә кереп кинәт үсә торган җинаятьчелекнең рәхимсез басымын үзенә ала. Шуңа да хокук сагында торучыларның һөнәрмәнлегенә, сабырлыгына һәм фидакарьлегенә тиешле бәяне бирергә кирәк: алар законлылыкның өстенлеген саклап кала, җинаятьчелекнең җәзасыз котыруына юл куймауга ирешә, ә соңгы елларда криминоген хәлне күп кенә хәлиткеч позицияләр буенча тотрыклыландыра алалар. Хәзерге вакытта илдә килеп туган конкрет сәяси һәм икътисадый хәлдән, җәмгыятьнең, криминоген хәлнең дә кискенләшүе белән бергә гел начарлана бара торган матди һәм социаль хәленнән чыгып, милиция үз эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтү буенча реаль чаралар күрә.

Без, Татарстанның хокук тәртибе органнары өчен агымдагы елның июлендә ТР Эчке эшләр министрлыгы коллегиясендә махсус концепция кабул ителү җинаятьчелеккә каршы көрәш бурычларын сыйфат ягыннан гамәлгә ашыруның сизелерлек, хәтта борылыш моменты да булды. Аның буенча, милициянең төп бурычы булып, элеккечә үк җинаятьчелеккә каршы көрәш кала, тик концепциядә аның төп юнәлешләренең бүгенге шартларга яраклаштырылган принципиаль үзенчәлекләре аерым билгеләнә. Бу исә безгә эшебезнең озак сроклы стратегиясен һәм тактикасын билгеләргә мөмкинлек бирә. Алар җинаятьчелекнең котырып үсүеннән генә түгел, җинаятьләрнең характеры үзгәрүдән дә килеп чыга: җинаятьчелекнең табыш алу максаты белән эшләнә торган икътисадый җинаятьләргә таба зур тизлек белән күчү процессы бара; наркобизнес торган саен активлаша; ниһаять, һәм монысы аеруча борчый, җинаятьчел даирәләрнең власть структуралары, кайбер очракларда хәтта хокук саклау органнары белән дә кушылуы куркынычы күз алдында.

Ә шул ук вакытта җинаятьчелеккә каршы көрәшне көчәйтүдә милициягә тышкы резервларны (штат санын арттыру) тартуга өметләнергә урын да юк, хәер, анысы, соңгы еллар практикасы күрсәткәнчә, үзен акламый да. Шуңа да бу концепциядә түбәндәге юнәлешләр өстенлекле итеп билгеләнә. Беренчесе - эчке эшләр органнарында кадрлар сәясәтенең яңасын эшләү. Бу, һичсүзсез, ул максатларга мораль һәм матди стимулларның барлык төрләрен дә кулланып, милиция кадрларын сайлап алу, әзерләү һәм тәрбияләүне көчәйтү дигән сүз. Икенчесе - идарә һәм оештыру - штат эшчәнлеген камилләштерү. Бу көчләрне яңадан бүлүне, бүлекне, беренче чиратта турыдан - туры криминаль милицияне кадрлар белән ныгытуны, бердәм мәгълүмат - анализ хезмәте төзүне, элегрәк кулланылган шаулы операцияләрдән баш тартуны, кәгазь - бюрократия волокитасын һ.б. минимумга кадәр киметүне күздә тота. Өченчесе - милиция эшен беренче чиратта авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрнең артуына китерүче оешкан җинаятьчел төркемнәрне ачыклап юк итүгә юнәлтү. Дүртенчесе - милициянең барлык служебаларының башка хокук саклау органнары - таможня, салым полициясе белән бердәм һәм төгәл эш итүен тәэмин итү. Барлык бу чаралар милициягә җинаятьчелеккә каршы көрәштә, җәмгыятьнең иминлеген һәм гражданнарның тынычлыгын тәэмин итүдә сыйфат ягыннан сикереш ясарга мөмкинлек бирер дип ышанабыз.

Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлегенә килгәндә, бездә бу концепцияне гамәлгә ашыру юнәлешендә беренче адымнар ясалды инде. Иң элек бу кадрларга кагыла. Һөнәри таләпләргә туры килмәгәннәре һәм эшкә салкын караулары өчен 12 кеше чыгарылды. Бер үк вакытта эчке күчерүләр исәбенә төп служебалар тәҗрибәле, намуслы хезмәткәрләр белән ныгытылды. Бүлекнең эшкә сәләтлелеге сизелерлек үсте, бу хакта нәтиҗәләр дә ачык сөйли: агымдагы елда барлык теркәлгән үтерүләр, көчләүләр, барлык урлаулар да диярлек ачылды. Барлык җинаятьләрнең өчтән берен тәшкил итүче урлауларны ачуга шәхси состав аеруча күп көч куя. Бу уңайдан үсмерләр тарафыннан эшләнә торган урлау җинаятьләренең артуы безне бигрәк тә хафага сала, ул ата - аналарны да борчырга тиеш.

... Форсаттан файдаланып, беренче көннән үк милициягә һәрнәрсәдә сизелерлек ярдәм күрсәтә башлаган район хакимияте башлыгына рәхмәт белдерәсем килә. Бүлекнең яңа бинасы төзелә башлады һәм ул киләсе елда төгәлләнер дип уйлыйбыз. Бүгенге көндә бүлек хезмәткәрләре тотрыклы рәвештә хезмәт хакы, бераз гына соңарып паек акчасы алалар, торак, газ, электр энергиясе, коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрдә ташламалардан файдаланалар. Аларга отпуск вакытында бушлай йөрү хокукы сакланды, санаторий - курорт дәвалавына җибәрү мөмкинлеге бар. Бүлекнең автотранспорт белән тәэмин ителеше начар түгел, ягулык мәсьәләсе җайга салынган. Әле менә күптән түгел генә тулы комплектта яңа өс - баш алдык. Болар барчасы безгә иртәгәге көнгә өмет белән карарга һәм куелган бурычларны җаваплылык тоеп үтәргә мөмкинлек бирә.

Сүземне йомгаклап, милиция хезмәткәренең намус кодексына тугры калып, хокук тәртибен саклауның кыен, кайчак куркыныч та хезмәтен һөнәрмәннәрчә, йөрәге һәм вөҗданы кушуы буенча башкаручы хезмәткәрләребезнең кайберләрен генә булса да телгә алып китәсем килә. Иң беренче сүзем милиция подполковнигы В.Л.Гаврилов җитәкчелегендәге криминаль милиция турында. Биредә оперуполномоченный И.Н. Чернов эштә аеруча нәтиҗәлелек күрсәтә, яшь оперлар Д.Вәлиев, И.Гайнетдинов та өметле. Икътисадый җинаятьләргә каршы көрәштә милиция майоры Ю.Е.Кузьмин әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирешә. Җәмәгать иминлеге милициясен күптән түгел генә тәҗрибәле һәм принципиаль хезмәткәр, милиция майоры Н.Н.Корбанов, ә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау бүлеген милиция капитаны М.М. Зәйниев җитәкли башладылар. Участок инспекторлары - майорлар Г.Ю.Чуркин, М.М.Сәгыйров һәм К.Т. Гобәйдуллин, милиция лейтенанты С.А.Бобров, быел гына да берничә җинаятьчен җинаять урынында тоткан милиционер Н.В.Тимаков, шулай ук шофер - милиционерлар Н.Н.Ульдяков, В.Н. Еремеев, П.И.Васильев, Р.Хөсәеновны да телгә алмыйча китә алмыйм. Безнең хатын - кыз хезмәткәрләребез - өлкән сорау алучы Р.Р.Котдусова, төзәтү эшләре бүлегендә өлкән хезмәткәр Л.В.Еменькина, паспорт - виза хезмәте өлкән инспекторы Е.В.Ефремова, өлкән тикшерүче Н.Х. Сөләйманова, тикшерүчеләр О.В.Купцова, Л.Р.Мостафина аерым хөрмәткә лаеклар.

Алар барысы да бәйрәм көннәрендә дә үз постларында булдылар, алар өчен ял көне дигән нәрсә дә - сирәк хәл. Шуңа да барлык милиция хезмәткәрләренә дә ару - талусыз эшләре өчен рәхмәт белдерәбез, аларга һөнәри уңышлар, тазалык - саулык, гаилә иминлеге телибез.

---

# «РАЙОННЫҢ АЛТЫН ФОНДЫ»

(Ахыры. Башы 1нче биттә).





Очрашу җылы атмосферада, чәй табыны артында җыр - бию белән аралашып, эчкерсез сөйләшүләр белән дәвам итте. Һәр кунакның искә алырлык хатирәсе бар иде. Н.А.Калипаровның да, 30 еллык баш ветврач В.В.Казаковның да, К.Ә.Калмурзинның да, башкаларның да. Аларның бит һәммәсе - үз өлкәсендә хезмәтне җигелеп тарткан, район тормышының үзәгендә кайнаган кешеләр. Шуңа тормышларның ары таба ниндирәк юнәлеш алуы турында борчылулары да табигый. Фатих Сәүбәнович шуны аңлаганлыктан, һәр күтәрелгән темага үз күзлегеннән чыгып, иренмичә аңлатма бирә барды. Сөткә, майга бәя артумы? Бу - табигый хәл. Ул халыкны авыр хәлгә кую теләгеннән түгел, ә авыл хуҗалыгы продукциясенә реаль бәя кую омтылышыннан туган нәрсә. Терлекләрнең баш саны кимиме? Юк, бары без хуҗалыкларга табышлы тармакны сайлап үстерү мөмкинлеге бирәбез...

Өстәл артында хуҗалык итүне реформалаштыру, орлык әзерләү, икмәк үстерү турында да сүз булды, хәтта сәламәт буын үстерү хакында да сөйләделәр. Һәм бу темаларның барысы да кызыксынып тыңланды, җитдилек белән уртага салып сөйләшенде. Сизелеп торды: өлкән алтын фонд әле үз сүзен әйтерлек, үз буыныың иң уңай тәҗрибәсен яшьләргә җиткерергә, тормышта үзенә файдалы эш табарга биш куллап риза!

Очрашу табыны артында чагыштырмача яшь өч хатын - кыз белән кунакларны хакимият башлыгы үзе таныштырды: болар - "Өмет" агрофирмасының "Агрокультура" кооперативының атаклы дуңгыз караучылары Галина Кузьминична Виноградова, Нина Ивановна Ефимова, Валентина Федоровна Кульметьева иде.

- Юллар төшкәч, бер җай табып, без сезне бу хуҗалыкка алып барып, аларның хезмәте белән таныштырырбыз әле. Сокланып туймаслык эшлиләр кызлар!- диде Фатих Сәүбәнович.

Әйе, районның бүгенге тормышында горурланырлык кешеләр, гүзәл эшләр шулай ук байтак иде. Өлкәннәр су, газ өчен, яңа үсеп чыккан социаль - мәдәни биналар өчен чын күңелдән рәхмәт укыдылар.

- Без бу очрашуларны даими итәргә тырышачакбыз,- диде хушлашканда Фатих Сәүбәнович һәм өлкәннәргә рәхәтләнеп ял итәргә тәкъдим итте, тагы бер кат бәйрәм белән котлады. Ә бу бәйрәмнәрнең һәр икесе - Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Октябрь революциясе көне бик кадерле иде кунакларга. Алар бит Октябрь вакыйгасын тарихи хата итеп түгел, ә рухи һәм матди хөрлек китергән бөек көн дип яшәделәр, шушы идеалларына тугры хезмәт иттеләр һәм беркайчан аңардан оялмаячаклар да. Бүгенге очрашуда да бер - берсенең, яшь буынның күзләренә кыю, туры карадылар, эчкерсез җылылык белән аралаштылар, зур рәхмәт хисләре белән таралдылар. Әмма озакка түгел, дип уйладым: җаваплы һәм тынгысыз буын кешеләренең күбесе хакимият бинасына үз тәкъдимнәре, фикерләре белән килер, һичшиксез килер әле! Ә җәмгыятькә өлкәннәр зирәклеге, акылы, киңәше беркайчан да артык булмас.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# TV

## СРЕДА

### 11 НОЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.00,20.00 "Жиһан"**
**18.10 "Батулла дәресләре"**
**18.30 "Шаян - шоу"**
**19.00 "Адашкан мәхәббәт"**
**19.45 "Әлли - бәлли - бәү"**
**20.20 Музыка ТРТ**
**20.30,22.50 Новости**
**20.50 "Социальные приоритеты"**
**21.20 "Стиль - 7"**
**21.40 "Французская революция"**
**22.40 "Из личной жизни"...дома"**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.35 Новости.
9.15 17.00 "Жестокий ангел".
10.15 Тема.
11.00 Хоккей.
11.50 Домашняя библиотека.
12.15 "Вместе".
13.05 "Анискин и Фантомас".
14.30 "Альберт - пятый мушкетер".
15.15 "Новые приключения Синдбада".
15.45 Зов джунглей.
16.10 Детские анекдоты.
16.30 ...До шестнадцати и старше.
18.15 Угадай мелодию.
18.45 Час пик.
19.00 Человек и закон.
19.45 "Скарлетт".
20.45 Спокойной ночи,малыши!
21.00 Время.
21.50 "Красная жара".
23.50 Э.Радзинский. "Предсказание Сталина".

**«РОССИЯ»**

7.00 9.30 9.50 Доброе утро, Россия!
9.15 19.30 23.45 "Дежурная часть".
9.35 Телеигра "Программа передач".
10.00 "Санта-Барбара".
10.45 "Музыка, музыка...".
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 "Графиня де Монсоро".
12.20 Старая квартира.
13.35 "Магазин на диване".
14.35 "Династия II: семья Колби".
15.20 "Богатые и знаменитые".
16.10 Мультфильмы.
16.30 Тяжелая атлетика.
17.30 "Башня".
18.10 "Ко мне, Мухтар!"
19.40 История одного события.
20.35 Подробности.
20.45 Сам себе режиссер.
21.15 "Криминальный квартет".
22.45 "Агата Кристи. Пуаро".



**РИО**

17.10 ДИСК-канал. 17.45 Дорожный патруль. 18.00 ТСН-6. 18.30 Юмористический сериал "Грейс в огне IV", 2 серия. 19.00 Сериал "Защитница", 2 серия. 20.00 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.30 Ток-шоу "Я САМА". "Я за него в ответе". 21.25 Сериал "Зов убийцы". "Чистая смерть". 22.25 "В мире людей". 23.05 Юмористический сериал "33 квадратных метра. Дачные истории", 6 серия. 23.35 Дорожный патруль. 23.50 ТСН-6. 0.00 Те Кто. 0.15 ДИСК-канал. 0.50 "Знак качества". 1.00 Ночной сеанс. "Город-алфавит".

## ЧЕТВЕРГ

### 12 НОЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.00"Жиһан"**
**18.10 "Агым"**
**18.30 Хоккей. Чемпионат РХЛ. "Ак Барс" (Казань) "Молот" (Пермь). Прямая трансляция. В перерывах - "Әлли - бәлли - бәү", "Жиһан"**
**20.50 Банк "Заречье" информирует**
**21.00 "ГАИ - информ"**
**21.20 "Точка опоры"**
**21.40 "Французская революция"**
**22.30 "БКЗ приглашает"**
**22.50 Новости**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.20 Новости.
9.15 17.00 "Жестокий ангел".
10.20 Человек и закон.
11.05 Клуб путешественников.
11.50 Домашняя библиотека.
12.15 "Вместе".
13.05 "И снова Анискин". 1-я серия.
14.30 "Альберт - пятый мушкетер".
15.15 Сериал "Новые приключения Синдбада".
15.45 Классная компания.
16.05 Умники и умницы.
16.30 ...До шестнадцати и старше.
18.15 Эти забавные животные.
18.45 Час пик.
19.05 "Чтобы помнили..."
19.45 "Скарлетт".
20.45 Спокойной ночи,малыши!
21.00 Время.
21.50 "Берегись автомобиля".
23.35 Э.Радзинский. "Предсказание Сталина".

**«РОССИЯ»**

7.00 9.30 9.50 Доброе утро, Россия!
9.15 19.30 23.45 "Дежурная часть".
9.35 Телеигра "Программа передач".
10.00 "Санта-Барбара".
10.45 "Музыка, музыка...".
11.00 14.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 "Графиня де Монсоро".
12.20 Старая квартира.
13.30 "Магазин на диване".
14.35 "Династия II: семья Колби".
15.20 "Богатые и знаменитые".
16.15 "Сказочный полдник".
16.30 Тяжелая атлетика.
17.30 "Башня".
18.10 "Прямая трансляция".
19.40 История одного события.
20.35 Подробности.
20.45 "Два рояля".
21.30 "Грязные танцы".
21.55 "Самозванцы".
22.55 "Притворщик".

**РИО**

17.10 ДИСК-канал.
17.45 Дорожный патруль.
18.00 ТСН-6.
18.30 Юмористический сериал "Грейс в огне IV", 3 серия. 19.00 Сериал "Защитница", 3 серия. 20.00 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.30 О.С.П.-Студия. 21.25 Сериал "LEXX". "Питающая форма". 22.30 "В мире людей". 23.05 "OBOZZZ"-шоу. 23.35 Дорожный патруль. 23.50 ТСН-6. 0.00 Те Кто. 0.15 ДИСК-канал. 0.50 "Знак качества". 1.00 Ночной сеанс. "Массажистка".

## ПЯТНИЦА

### 13 НОЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.00,20.00 "Жиһан"**
**18.10 "Татарстан Республикасы Дәүләт Советында"**
**18.30 "Дин һәм тормыш"**
**18.50 "Мәчетләребез"**
**19.00 "Иртә түгел, соң түгел"**
**19.45 "Әлли - бәлли - бәү"**
**20.20 Музыка ТРТ**
**20.30,22.50 Новости**
**20.50 "Бизнес ТВ"**
**21.20 "В Госсовете Республики Татарстан"**
**21.40 "Дамы приглашают кавалеров"**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.10 Новости.
9.15 17.00 "Жестокий ангел".
10.15 "Чтобы помнили...".
10.55 В мире животных .
11.30 Смак.
11.50 Домашняя библиотека.
12.15 "Вместе".
13.05 "И снова Анискин".
14.30 "Альберт - пятый мушкетер".
15.15 "Старая, старая сказка".
18.15 Джентльмен-шоу.
18.45 Играй, гармонь любимая!
19.15 Здоровье.
19.45 Поле чудес.
20.45 Спокойной ночи,малыши!
21.00 Время.
21.50 "Хозяин тайги".
23.25 Э.Радзинский. "Предсказание Сталина".
00.30"Пропажа свидетеля".

**«РОССИЯ»**

7.00 8.30 9.30 9.50 Доброе утро, Россия!
8.15 "Тысяча и один день".
9.15 19.30 0.30 "Дежурная часть".
9.35 Телеигра "Программа передач".
10.00 "Санта-Барбара".
10.45 "Музыка, музыка...".
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 "Графиня де Монсоро".
12.20 Старая квартира.
13.30 "Магазин на диване".
14.30 "Династия II: семья Колби".
15.15 "Мир здоровья".
15.20 "Богатые и знаменитые".
16.10 "Геракл у Адмета".
16.30 0.45 Тяжелая атлетика.
17.30 "Башня".
18.10 "Долгая счастливая жизнь".
19.40 История одного события.
20.35 Подробности.
20.45 "Городок".
21.15 "Осторожно, модерн!".
21.45 Музыкальный ринг.
23.20 "Театр + TV".

**РИО**

17.10 ДИСК-канал. 17.45 Дорожный патруль. 18.00 ТСН-6. 18.30 Юмористический сериал "Грейс в огне IV", 4 серия. 19.00 Сериал "Защитница", 4 серия. 20.00 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.30 Ток-шоу "АКУЛЫ ПОЛИТПЕРА". 21.05 КИНОТЕАТР ТВ-6. Боевик "Штурмовик". 22.45 Сериал "Голод". "Шаги". 23.20 Дорожный патруль. 23.35 ТСН-6. 23.45 Те Кто. 0.05 ВЕЧЕРИНКА ИЗ "ЦЕНТРА". 1.45 Ночной сеанс. Кристиан Слейтер в боевике "Каффс".

## СУББОТА

### 14 НОЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**17.00 Хоккей. Чемпионат РХЛ. "Ак Барс" - (Казань) - "Спартак" (Москва). Прямая трансляция**
**19.30 "Сәлам юллыйм"**
**20.00 "Атна"**
**20.30 Новости**
**20.50 "У зеленого камина"**
**21.20 "Видеоспорт-авто"**
**21.40 "Можно мечтать всегда"**

**ОРТ**

8.00 "Шестой".
9.20 13.05 Мультфильм.
9.45 Слово пастыря.
10.00 15.00 18.00 0.00 Новости.
10.15 Домашняя библиотека.
10.35 "Чердачок братьев Пилотов".
11.10 "Утренняя почта".
11.45 "Каламбур".
12.20 Смак.
12.40 "Музыка русской живописи".
13.30 "Это случилось в милиции".
15.15 "Цивилизация".
15.45 В мире животных.
16.30 Песня-98.
17.15 Как это было.
18.20 "Золотая лихорадка".
18.55 "Ералаш".
19.15 "Петровка, 38".
21.00 Время.
21.50"Секретные материалы".
23.30 Служба спасения.
00.20 "Невинный".

**«РОССИЯ»**

8.00 9.30 Мультфильм.
8.20 "Собачье счастье".
10.00 Доброе утро, Страна!
10.50 "Сто к одному".
11.30 "Любовь с первого взгляда".
12.00 Подиум д"Арт.
12.30 "Домашние хлопоты с Н. Варлей".
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре".
14.00 20.00 Вести.
14.30 "Марьина роща".
15.00 "50х50: буду звездой!".
16.10 "Закон и порядок".
17.00 "Стар" и "млад".
18.00 Моя семья.
19.00 "Малиновый звон".
20.30 "Добрый вечер".
21.15 "Творческий вечер композитора И. Крутого".
23.50 "Жажда страсти".
1.10 Тяжелая атлетика.

**РИО**

8.00 Программа передач.
8.05 Дорожный патруль.
8.15 ДИСК-канал.
8.50 УТРО ПРОДЛЕННОГО ДНЯ.Мультфильмы. "Веселая карусель", "История одного города". 9.15 Мультсериал "Серебряный конь", 11 серия. 9.45 Сериал "Флиппер II", 11 серия. 10.35 Мультсериал "Альф", 11 серия. 11.00 Путешествия с "Национальным Географическим Обществом". "Полярный волк". 12.00 Маленькое утреннее шоу "ЗК". 12.20 ТЕЛЕМАГАЗИН "Спасибо за покупку!". 12.30 КИНОТЕАТР ТВ-6. Памяти Ролана Быкова. "Звонят, откройте дверь". 14.00 ГАЛА-КОНЦЕРТ звезд эстрады на Тверской. 15.35 Ток-шоу "Я САМА". "Я за него в ответе". 16.35 Сериал по выходным "Робин Гуд", 25 серия. 17.35 ТЕРРИТОРИЯ ТВ-6. Программа А.ПОЛИТКОВСКОГО. 18.05 Дорожный патруль. Расследование. 18.20 КИНОТЕАТР ТВ- 6. Памяти Ролана Быкова. "Приключения Али-Бабы и 40 разбойников", 1-2 серии. 20.55 СКАНДАЛЫ НЕДЕЛИ. 21.30 СВ ШОУ. 22.00 КИНОТЕАТР ТВ-6. Антонио Бандерас в фильме "Короли Мамбо". 23.55 Дорожныйпатруль. 0.10 ТСН-6.



## ВОСКРЕСЕНЬЕ

### 15 НОЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00 - 8.00 "Чулпан"**
**14.15 "Милли хәзинәләрдән". И.Гази. "Онытылмас еллар". Телевизион спектакль 2 - нче серия**
**17.00 Баскетбол. Суперлига. "Уникс" (Казань)- "Автодор" (Саратов)**
**18.40 "Ел кешесе" Академик Марс Михайлов**
**19.00 "Бәйрәм белән, дуслар!"**
**20.30 "ТОН"**
**21.00 "Автокалейдоскоп"**
**21.20 Музыка ТРТ**
**21.30 "Видеоспорт"**
**21.40 "Баскетбол, мы тебя любим!"**
**22.10 "Бизнес ТВ"**
**22.40 "Досье 02"**

**ОРТ**

8.00 "Сыщик петербургской полиции".
9.30 "Дисней-клуб".
10.00 15.00 18.00 0.35 Новости.
10.15 "Непутевые заметки" Дм.Крылова.
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Армейский магазин.
12.30 Играй, гармонь любимая!
12.55 Крестьянские ведомости.
13.25 "Все путешествия команды Кусто" .
14.20 Смехопанорама.
15.15 Клуб путешественников.
16.05 Футбольное обозрение.
16.35 "Дисней-клуб"
17.30 "Помню... люблю..."
18.15 "Колесо истории".
19.05 "Ералаш".
19.20 Х.ф. "Огарева,6".
20.55 Киноафиша.
21.00 Время и мы.
22.00 "Между ангелом и бесом".
0.05 "Абажур".
0.55 "Семья ядерного века".

**«РОССИЯ»**

8.00 Мультфильм.
8.30 "Служу Отечеству".
9.30 "Почта РТР".
10.00 Доброе утро, Страна!
10.30 Сам себе режиссер.
11.00 "Аншлаг".
11.30 "Городок".
12.00 Русское лото..
12.40 "Мир книг с Леонидом Куравлевым".
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре".
14.00 Вести.
14.30 Федерация.
15.10 Парламентский час.
17.00 Диалоги о животных.
18.00 Старая квартира.
19.15 Совершенно секретно.
20.00 Зеркало.
20.55 "Простодушный".
22.40 "К-2" представляет.
23.35 "Дежурная часть".
0.00 Тяжелая атлетика.

**РИО**

8.00 Программа передач. 8.05 Дорожный патруль. 8.15 ДИСК-канал. 8.50 УТРО ПРОДЛЕННОГО ДНЯ.Мультфильмы. "Троллейбус под парусом", "Упущенная галактика". 9.05 Мультсериал "Серебряный конь", 12 серия. 9.35 Сериал "Флиппер II", 12 серия. 10.25 Мультсериал "Альф", 12 серия. 10.55 Путешествия с "Национальным Географическим Обществом". "Путешествие к забытой реке". 12.00 ШЕСТЬ НОВОСТЕЙ НЕДЕЛИ. 12.25 Шоу еды "ПАЛЬЧИКИ ОБЛИЖЕШЬ". 12.55 Ток-шоу "СДЕЛАЙ ШАГ". 13.55 КАНОН. 14.20 ТЕЛЕМАГАЗИН "Спасибо за покупку!". 14.40 "О.С.П." - студия. 15.35 Шоу Артура КРУПЕНИНА "МУЖСКОЙ КЛУБ". 16.35 Сериал по выходным "Робин Гуд", 26 серия.
17.35 "Звезды о звездах". Вика Цыганова.
18.05 Дорожный патруль. Сводка за неделю. 18.25 "ВЫ-ОЧЕВИДЕЦ". 19.00 Аналитическая программа "ОБОЗРЕВАТЕЛЬ".
20.00 КИНОТЕАТР ТВ- 6. Комедия Л.Гайдая "Кавказская пленница".
21.40 СПОРТ НЕДЕЛИ.
22.10 "Радио хит".
23.25 Ночной сеанс. Ирен Жакоб в фильме "Двойная жизнь Вероники".

# КЕМ ТЕЛӘСӘ, ШУНЫ ЧАКЫРАБЫЗ

Шахмат бик мавыктыргыч уен бит ул. Без, шахмат ветераннары өчен ул - бетмәс - төкәнмәс яшәү чыганагы, безгә яшәргә һәм эшләргә дә, картаймаска да булыша ул. Рухи яктан гына түгел, физик яктан да, чөнки шахмат белән чынлап торып шөгыльләнер өчен эшеңне дә, ялыңны да дөрес оештыра белергә кирәк.



Шахмат олысына да, кечесенә дә шатлык китерә. Шуның белән ул икеләтә кадерле. Балалар - яшүсмерләр физик хәзерлек клубында берничә ел инде шахмат һәм шашка түгәрәге эшли. Ул ике сменада оештырылган: шимбә һәм якшәмбедән кала иртәнге 8дән 11гә кадәр, төштән соң - 1дән 4кә кадәр. Бу түгәрәкләргә мәктәп балалары йөри ала, хастаханәдән медицина белешмәсе генә алып килергә. Занятиеләр түләүсез.

Шахмат буенча шәһәр беренчелегенә зурлар арасында шәхси һәм команда ярышларына язылу да бара. Бу уеннарда теләгән һәркем катнаша ала. Группаларның туплануына карап ярышлар ноябрьнең икенче декадасында узар дип көтелә.

Язылу балалар һәм яшүсмерләр физик хәзерлек клубының шахмат бүлмәсендә үткәрелә. Без сезне көтәбез. Рәхим итегез!

**А. КОСТИН.**


*13 ноябрьдә район мәдәният йортында*

**Красноярск циркы яңа программа белән.**

**Башлана**

***10, 14, 18 сәгатьләрдә.***

***Билет хакы 15 сум.***

***Программада цирк артистлары белән бергә: дөя, аю, буар елан, варан, маймыллар, тавыклар, күселәр.***

***Күмәк заявкалар өчен тел.: 2-16-55.***

***Билетлар буенча лотерея уйнатыла.***

***Рәхим итегез!***






***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

***Бездә генә!***

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 13нче, 27нче ноябрьдә, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


# ИСМӘГЫЙЛЬ ИСХАК УЛЫ ТУИШЕВ



1998 елның 5нче ноябрендә гомеренең 73нче яшендә Бөек Ватан сугышында катнашкан, хезмәт ветераны Исмәгыйль Исхак улы Туишев каты авырудан соң вафат булды.

И.И.Туишев 1925 елның 25 ноябрендә Татарстан АССРның Октябрь районы Кизләү авылында туган.

Үзенең хезмәт юлын 1949 елдан Кизләү сельпосы сатучысы булып кулланучылар кооперациясе системасында башлап җибәргән. 1963 елның февраленнән башлап пенсиягә киткәнче район хәзерләүләр конторасы директоры булып эшләгән. 22 ел буена шушы вазифаны башкарып, ул хәзерләүләр эшчәнлеген һәм тулаем алганда кулланучылар кооперациясен үстерүгә зур өлеш кертте. Эшләү дәверендә ул үз - үзенә һәм кул астында эшләүчеләргә карата таләпчән булды һәм кешеләр турында кайгыртуны һәрвакыт беренче урынга куйды.

Сугышны кичергән, фронтта яраланган булуга карамастан, ул бетмәс - төкәнмәс энергиягә ия булган, үзенең тирә- юнендәгеләргә рух күтәренкелеге бирергә сәләтле шәхес иде.

Аның сугышчан хезмәтләре күп кенә медальләр һәм II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бәяләнгән.

Исмәгыйль Исхак улы Туишевның якты истәлеге аның белән бергә яшәгән һә[м] эшләгән һәммә кешенең күңелендә мәңге сакланыр.

**Ф.С.Сибагатуллин, Ю.В.Терентьев, Ф.М. Дәүләтшин, А.Н.Ельченков, Ф.Р.Ногъманова, Ф.Н.Гобәйдуллин, Н.Б.Мөлеков, Н.Х.Абдуллин, Ю.А.Муракаев, М.С.Моратов, С.С.Идиятуллин, И.У.Гыйләҗев.**

# КЫЯМӘТ җитәчәк диләр...

## ә планлаштырылган кыямәт вакыты күптән узды инде

Гасыр тәмамланыр алдыннан "2000 елда кыямәт кубачак, дөнья бетәчәк" дигән сүзләр билгеле даирәләрдә бик еш яңгырый башлады. Көнбатыштагы кайбер дини тарикать җитәкчеләре кыямәт дәһшәтен күрмәс өчен кешеләрне кател нәфес кылырга, ягъни үз - үзләрен үтерергә өндәделәр. Бу чакырулар бушка китмәде: 1978 елда Джим Джонс җитәкчелегендәге 900 кеше үз - үзенә кул салды. 1993 елда Дэвид Кореш исемле Америка сектанты белән бергә 79 кеше үз - үзен үтерде. 1994 елда Швейцариядәге "Кояш храмы ордены" әгъзалары (53 кеше) үз - үзләрен үтерделәр. Ниһаять, күптән түгел "Heaven, s Gate" (Җәннәт капкасы) тарикатенең 39 мөриде үзләре теләп теге дөньяга китте.

"Кыямәт якынлаша" дигән фикер нәкъ менә христиан дине вәкилләре яки аннан аерылып чыккан секта әгъзалары арасында киң таралган. А.Гитлер, С.Хөсәен, М. Горбачев кебек хәрби диктаторлар һәм сәяси лидерлар ахырзаманның галәмәтләре буларак күрсәтелә.

Соңгы елларда бу исемлеккә АКШ президенты Билл Клинтон һәм "Майкрософт" компьютер ширкәте хуҗасы Билл Гейтс исемнәре өстәлде. Кайберәүләр Гейтсны ахырзаман алдыннан Җиргә киләчәк ялган пәйгамбәргә (мәсих) яки турыдан - туры шайтанга охшаталар. "Хоруфилек" (дөньяның яратылышын һәм Җир шарындагы бөтен тереклек ияләрен хәрефләр һәм саннар ярдәмендә аңлатучы дини карашлар системасы) традициясендә шайтан 666 санына туры килә. Билл Гейтсның исем - фамилиясе дә, хоруфиләр исәбе буенча, нәкъ шул санны бирә. Әлбәттә, бу мәгълүмат Гейтс турындагы шикләрнең артуына сәбәп булды. "Актуэль" журналындагы "Көтелгән дәҗҗал - Билл Гейтсмы?" исемле мәкаләдә болай дип язылган ( 1998 ел, февраль): "Кешелеккә караган бөтен символларны үз монополиясенә алырга тырышучы Билл Гейтс компьютер технологиясе ярдәмендә тарихны да яңадан яза ала. "Майкрософт" империясенең хуҗасы бөтен планетабызны контроль астына алырга ниятли. Ул китапханәләрне "Майкрософт" ширкәтенең бүлекләренә әйләндерә. Бөтен фоторәсемнәрне, картиналарны һәм сыннарны сатып ала. Билл Гейтсны җир йөзенә иңгән шайтан дип уйлыйлар. Аның исеме 666 санына туры килә. Адольф Гитлер һәм Иосиф Сталин исемнәре дә 666га туры килә".

Клинтонны исә Инҗил китабындагы түбәндәге өзектә китерелгән образга нисбәт итәләр: "Дөньяның падишаһлары аның белән җенси әхлаксызлык баткагына төштеләр. Дөньяның сәүдәгәрләре аның хәтсез бозыклыгы аркасында баедылар. Җенси әхлаксызлыкка төшкән һәм бозыклык эчендә яшәгән дөнья падишаһлары аны яндырган утның төтенен күргәч, кычкыра - кычкыра елаячаклар". Бу текстны шәрехләүчеләр фикеренчә, андагы "җенси әхлаксызлыкка төшкән падишаһ" - Клинтон үзе, баеган сәүдәгәрләр исә - хәзерге корал сатучылар.

### 2000 ЕЛ ҺӘМ ЗИЛЗИЛӘ

2000 елда кыямәт кубачагына француз Эдгар Кайс (1877 - 1954) та ышанган. Ул 1958 - 1998 еллар эчендә булачак берничә вакыйга турында күрәзәлек кылган. Аныңча, 1980 - 2000 елларда - табигатьнең ахырзаманга әзерлек чоры. Кайсның фаразына караганда, 2000 елда дөньяда ифрат көчле җир тетрәү булачак.

"Сабах" газетасының былтыр 5 май санында шаккаткыч хәбәр басылган иде. Анда болай диелгән: "2000 елның 5 маенда Җир шары, Кояш, Ай һәм тагын биш планета һәрберсе, үз орбитасыннан чыкмаган хәлдә, "бер сафка" тезелеп урнашачак. Мондый хәл беренче тапкыр Мисырда фиргавеннәр хөкемдарлыгы дәверендә булган. Бу күк җисемнәренең тарту көчләре бер - берсе белән берләшү нәтиҗәсендә дөньяда зур афәтләр: янартау атулары, җир тетрәүләр һ.б. шуның ише афәтләр булачак. Бу карашны инглиз галиме Джулиан Солт алга сөрә. Аныңча, 2000 елның 5 маенда океан сулары кимендә 1,5 чакрымга күтәреләчәк. Солт 1812 елда Юпитер, Сатурн, Уран һәм Нептунның үз орбиталарында бер сафка тезелүләре сәбәпле Җирнең Көньяк ярымшарында җәйнең бик суык булуын хәтергә төшерә".

### НОСТРАДАМУС ҺӘМ 2000 НЧЕ ЕЛ

Христиан галимнәре һәм дин сектантларының 2000 елны кыямәт вакыты итеп күрсәтүләренең төп сәбәпчесе, мөгаен, мәшһүр күрәзәче Нострадамустыр (XYI гасырда яшәгән). Ул 2000 ел турында болай яза: "2000 елның октябрендә Җир шары бик кискен хәрәкәткә киләчәк, җирнең тарту көче югалган кебек тоелыр, бөтен дөнья даими караңгылыкка чумар". Бирердә шуны әйтергә кирәк: хәзерге астрономнар 2000 елның маенда берничә планетаның үз орбиталарында бер сафка тезеләчәге һәм шул сәбәпле җирдә сейсмик активлык арту ихтималы турында язалар. Ягъни галимнәр Нострадамусның фаразын билгеле мәгънәдә раслыйлар кебек.

Төркиядәге "Иегова шаһитләре" сектасы вәкиле Мәтә Сүәр "Актуэль" журналы хәбәрчесе белән әңгәмәдә болай дигән: "Бу дөнья, һичшиксез, бетеп бара. Ул бетүгә йөз тоткан. Көнен - сәгатен тәгаен белмибез, ләкин бик якын киләчәктә булыр бу. Көтәбез".

Шулай итеп, шактый күп кешеләр 2000 елны кыямәт булачак дип фараз итә. Ләкин бу фаразларга бер төзәтмә кертәсе бар. Мәгълүм ки, тарихчы Дионис Экзигус 525 елда Хәзрәте Гайсәнең туган елын билгеләгәндә хата ясый һәм Милади тәкъвимне (безнең эраны) Гайсәнең туган вакытыннан дүрт ел соңрак башлап җибәрә. Шуңа күрә кешелек дөньясы чын 2000нче елны моннан ике - өч ел элек узып китте инде.Ягъни планлаштырылган кыямәт күптән булган булыр иде инде. Соңгы сүзебез шул: киләчәк турында төгәл мәгълүматны фәкать һәм фәкать Аллаһ Тәгалә генә белә.

**Айдоган Ватандаш.**
**("Заман -Татарстан" нан).**

Татреспотребсоюз идарәсе, хәзерләүләр идарәсе коллективы Нурлат райпосы хәзерләүләр конторасының элеккеге директоры **Исмәгыйль Исхак улы ТУИШЕВ**ның вафат булуы сәбәпле мәрхүмнең туганнарының һәм якыннарының олы кайгысын уртаклаша.

Нурлат район кулланучылар җәмгыяте идарәсе район хәзерләүләр конторасының элеккеге директоры, сугыш һәм хезмәт ветераны **Исмәгыйль Исхак улы ТУИШЕВ**ның вафат булуын тирән кайгы белән белдерә һәм мәрхүмнең якыннарының, туганнарының авыр хәсрәтен чын йөрәктән уртаклаша.


## БЕЛДЕРҮЛӘР, РЕКЛАМА

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч төстә Төньяк - Көнчыгыш микрорайонында йорт төзү өчен участок.** Козлов ур., 16 - 1 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә, тел.: 5-23-20.

***

**Азык - төлек базары янында 3 бүлмәле фатир.**
Тел.: 2-26-64.

***

**3 бүлмәле фатир.**
Адрес: Дружба ур., 74 - 24, кичке 5тән соң.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Завод җайланмалары ярдәмендә тәгәрмәчләрне шиплыйбыз. Гарантияле, сыйфатлы.**
Тел.: 5-35-91. Б - 97 сер. 288882 номерлы лицензия.

***

**"Надежда" кооперативы бетерелә.** 5-25-15 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.

**Килограммын 8 сумнан бакыр, 3 сумнан җиз, бронза, 2 - 5 сумнан алюминий калдыклары сатып алам.**
Адрес: Совет ур., "Татсельхозмонтаж" базасы.
А 0204 номерлы лицензия.



МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә 4338